**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«18» май 2022 ел Иштирәк авылы №20/4

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль бемлеге Советының 2021 елның 23 нояберендәге 16/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегендә инициатив проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Уставы нигезендә авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 23 нояберендәге 16/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегендә инициатив проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу һәм карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Җыелыш үткәрелә:

көндезге формада – көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм тавышка куелган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү өчен халыкның уртак катнашуы формасында».

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Г.С. Гарифуллина